ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

19 август 2026 ел

№ 8473

Башкарма комитетның 2026 елның 12 мартындагы 2325 номерлы Карары белән расланган Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2026 елның 12 мартындагы 2325 номерлы Карары белән расланган Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 пунктның икенче абзацында «5000» цифрларын «10000» цифрларына алмаштырырга;

2) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Муниципаль хезмәтне алдан башкару (проактив) режимында күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәт 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясында каралган алдан башкару (проактив) режимында күрсәтелми.»;

2) 3 нче кушымтада 1 пунктта «Шәхесне таныклаучы документ» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне таныклаучы башка документ яки «Биометрик персональ мәгълүматлардан файдаланып физик затларны идентификацияләүне һәм (яки) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуны тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмати технологияләрдән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүче

органнарда, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә идентификация һәм (яки) аутентификация юлы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов